ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17 нче йорт. Тел.3-44-22. Факс 3-44-14

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-44-22. Факс 3-44-14

КАРАР 04.09.2019

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ . ПР-178

**Педагогик хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә ай саен бирелә торган өстәмә түләү өчен Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының " Мәгариф идарәсе» МКУ акчаларын юнәлтү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетынын 2003 елның 30 апрелендәге 242 номерлы “Педагогик хезмәткәрләр – яшь белгечләргә Дәүләт ярдәме чаралары һәм социаль яклау турында” карары, Татарстан Республикасының 2018 елның 21 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасының 2019 елга, 2020 һәм 2021 нче елларга план чорына бюджеты турында”гы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы һәм Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты арасында төзелгән Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты бюджетына 2019 елда педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимул бирә торган өстәмә түләүләрне гамәлгә ашыру өчен субсидияләр бирү турында килешүне үтәү йөзеннән, Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Мәгариф учреждениеләренә, педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимул бирә торган өстәмә түләүләрне гамәлгә ашыру , максатчан субсидия бүлеп бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге максатларга бүлеп бирелгән акчалар хисабына Актаныш муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының ассигнованиясен 173 583,00 сумга арттырырга.

2.Килешү нигезендә бүлеп бирелгән акчаларның максатчан кулланылышын тәэмин итәргә.

3.Бюджет акчаларын куллануны контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районының финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

4. Әлеге карарны http//pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Актаныш муниципаль районының "интернет"мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны мәгариф идарәсе начальнигы вазыйфаларын башкаручы А.Р.Гимадиевка йөкләргә.

Житәкче вазыйфаларын башкаручы Л.Ф.Нурлыева